Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаятенә бәйле рәвештә Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацларының, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2022 елның 27 гыйнвары

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацларының, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый

нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.С. Мусин мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе башлыгының беренче урынбасары Л.Р. Шәрипова, шикаять белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча суд утырышына чакырылган белгеч — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенең муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы Е.Н. Смагина аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Т.Ә. Вәлиев Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацлары, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацлары нигезендә маневр фондының торак урыннары Россия Федерациясе Торак кодексының (алга таба шулай ук — Торак кодексы) 88, 106 статьяларында каралган очракларда һәм нигезләрдә маневр фондының торак урынын яллау килешүе буенча түләү хисабына түбәндәге чорга вакытлыча файдалануга бирелә:

1) муниципаль торак фондында социаль наем килешүләре буенча алар биләгән торак урыннар урнашкан йортка ясала торган капиталь ремонт яисә реконструкция тәмамланганчы;

2) түләттерү мөрәҗәгате нәтиҗәсендә банк яисә башка кредит оешмасы кредиты яки юридик зат тарафыннан торак урын сатып алуга бирелгән максатчан заем акчалары хисабына сатып алынган һәм кредитны яки максатчан заемны кайтаруны тәэмин итәр өчен залогка салынган торак урыннарын югалткан гражданнар белән исәп-хисаплар тәмамланганчыга кадәр, әгәр түләттерү мөрәҗәгате килгән вакытка мондый торак урыннар алар өчен бердәнбер торак урын булса;

3) бердәнбер торак урыны гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксызга әйләнгән гражданнарга.

Нигезләмәнең 4.2 пункты маневр фондының торак урыннары гражданнарга гариза нигезендә яки муниципаль торак фонды белән идарә итә торган оешманың реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау турында мөрәҗәгате яки залог тотучы булып торучы юридик зат мөрәҗәгате (алга таба — оешма мөрәҗәгате) нигезендә бирелүен күздә тота.

Нигезләмәнең 4.4 пункты нигезендә маневр торак фондыннан торак урын бирү турында гражданнарның гаризалары һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре кергән көннән алып 30 көн эчендә Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы (алга таба шулай ук — вәкаләтле орган) тарафыннан карап тикшерелә; кабул ителгән карар турында гражданнарга һәм оешмаларга әлеге карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, Т.Ә. Вәлиев үзенең хатыны, кызы һәм аның балигъ булмаган өч баласы белән гомуми мәйданы 26,05 кв. м булган тулай торак бүлмәсендә теркәлгән. Аның аз керемле дип танылган гаиләсе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак 2010 елның 19 февраленнән исәптә торган. Үзенең социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны алу перспективалары юк дип уйлап, мөрәҗәгать итүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенә үз гаиләсенә маневр фондының торак урынын яллау килешүе буенча түләү хисабына

вакытлыча файдалануга алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткән, әмма, Казан шәһәрендә гражданнарга вакытлыча яшәү өчен маневр фонды булдырылмавына бәйле рәвештә, аңа баш тартылган. Гражданин Т.Ә. Вәлиев әлеге баш тартуны законсыз дип саный, чөнки баш тарту өчен мондый нигез Нигезләмәдә каралмаган.

Мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә игътибар итә: Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы шикаять белдерелә торган икенче — бишенче абзацларның аерым нигезләмәләре белән билгеләнгән маневр фондының торак урыннарын яллау килешүе буенча түләү хисабына вакытлыча файдалануга бирү чорларын билгеләүче хокукый җайга салу, фактта, мондый торак урыннары алу хокукына ия гражданнар категорияләренең тулы исемлеген беркетә, шул ук вакытта, Торак кодексының 95 статьясындагы төп нигезләмәләрен бозып, законда каралган очракларда башка гражданнарны исәпкә алмый, аларга, аның фикеренчә, ул үзе дә кертелергә мөмкин. Шул нигездә гражданин Т.Ә. Вәлиев дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрне җирле үзидарә органнары карарларының законлы характеры турындагы конституциячел нормага туры килми дип саный.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Нигезләмәнең 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы үзара бәйле нигезләмәләр, маневр фондының торак урыннарын бирү процедурасын билгеләп, шуның белән бергә гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди нигезләрдә һәм нинди карарлар кабул ителергә мөмкин булуын күз алдында тотмый. Аның фикеренчә, күрсәтелгәннәр вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карарны үзенчә ирекле тәртиптә кабул итү мөмкинлеген калдыра, бу хокукый билгеләнешнең, тигезлекнең һәм гаделлекнең конституциячел принципларын бозуга китерә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Т.Ә. Вәлиев Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында

нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацларын, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә бүтән органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик

тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

— Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче —бишенче абзацларының аерым нигезләмәләре, алар, гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын билгеләп, гражданны шушы чорлар кысаларында мондый торак урыннары алу хокукына ия булган теге яки бу категориягә кертү өчен норматив нигез булып торган дәрәҗәдә;

— Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктлары, аларда гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди карарлар кабул ителергә мөмкинлеге мәсьәләсендә билгесезлек булган дәрәҗәдә.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия

Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

Торак законнары өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтләрен, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтләрен законнар белән бүлешү Торак кодексында беркетелгән, аның 5 статьясындагы 2 өлешендә торак турындагы законнар шул исәптән җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларыннан тора дип билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьялары нигезендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә, ул үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә, җирле үзидарә органнары муниципаль милеккә мөстәкыйль идарә итәләр. Тиңдәш нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12, 130 (1 өлеш) һәм 132 статьяларында беркетелгән.

Күрсәтелгән хокукый җайга салуга 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясе (Россия Федерациясе өчен 1998 елның 1 сентябрендә үз көченә кергән) нигезләмәсе тәңгәл килә, аның нигезендә җирле үзидарә органнары үзләренең вәкаләтләре өлкәсендәге һәм нинди дә булса башка хакимият органы карамагында булмаган теләсә нинди мәсьәлә буенча үз инициативасын гамәлгә ашыру өчен законда билгеләнгән чикләрдә тулысынча ирекле эш итәләр (4 статьяның 2 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, карамактагы мәсьәләләрне, вәкаләтләрне һәм компетенцияне кертеп, җирле үзидарәнең хокукый нигезен билгели һәм җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларын җайга сала. Әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 6 пунктлары нигезләмәләре шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә шәһәр округының муниципаль милкендәге мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итүне,

муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны кертә.

Шуңа охшаш җайга салу «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 6 пунктларында каралган.

Торак кодексының 14 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә шул исәптән махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибен билгеләү вәкаләте керә.

Федераль һәм республика законнарының китерелгән нигезләмәләре Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында (алга таба шулай ук — Устав) үсеш алган, ул Казан шәһәре Думасы — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы вәкаләтләре исәбенә Казан шәһәре муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен һәм махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибен билгеләү вәкаләтләрен керткән (28 статьяның 1 өлеше).

Уставның күрсәтелгән нигезләмәләре нигезендә Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән «Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында» Нигезләмә расланган.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул итеп, Казан шәһәре Думасы федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә караган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә нигезләнгән үз вәкаләтләрен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар

булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемнең торакка хокукын беркетә; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7 һәм 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Әлеге конституциячел нормалар 1948 елның 10 декабрендәге Кеше хокуклары гомум декларациясенең 25 статьясы һәм 1966 елның 16 декабрендәге Икътисадый, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 11 статьясы нигезләмәләренә тәңгәл килә, алар, лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак, һәркемнең торакка хокукын таныйлар.

Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары гражданнарның торакка хокукларын гамәлгә ашыру өчен үз вәкаләтләре чикләрендә шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан торак урыннарны яллау шартнамәләре буенча гражданнарга билгеләнгән тәртиптә торак урыннар бирәләр (3 пункт).

3.1. Торак кодексы «торак фонды» конституциячел-хокукый төшенчәсен конкретлаштырган (Россия Федерациясе Конституциясенең 40 статьясындагы 3 өлеш) һәм аны Россия Федерациясендәге барлык торак урыннар бергәлеге буларак билгеләгән (19 статьяның 1 өлеше); әлеге фондның бер өлеше — махсуслаштырылган торак фонды, ул гражданнарның аерым категорияләре яшәү өчен билгеләнгән дәүләт һәм муниципаль торак фондларының торак урыннар бергәлеге (19 статьяның 3 өлешендәге 2 пункты), аларга маневр фондындагы торак урыннар керә (92 статьяның 1 өлешендәге 3 пункты).

Торак кодексының 95 статьясы нигезендә маневр фондындагы торак урыннар түбәндәгеләргә вакытлыча яшәп тору өчен билгеләнә һәм бирелә: гражданнарга социаль яллау шартнамәсе буенча алар били торган торак урыннар урнашкан йортка капиталь ремонт ясауга яисә аны үзгәртеп коруга бәйле рәвештә (1 пункт); банк яисә бүтән кредит оешмасы исәбеннән йә торак

урынны алу өчен юридик зат тарафыннан бирелгән максатчан заем акчалары исәбеннән алынган һәм кредитны яисә максатчан заемны кире кайтару өчен закладка салынган торак урыннарны түләүгә алу нәтиҗәсендә торак урыннарын югалткан гражданнар, әгәр түләүгә алу вакытына мондый торак урыннар алар өчен бердәнбер булса (2 пункт); гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә бердәнбер торак урыннары яшәү өчен яраксыз булып калган гражданнарга (3 пункт); күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану нәтиҗәсендә торак урыннары яшәү өчен яраксыз булып калган гражданнарга (3.1 пункт); шулай ук законнарда каралган очракларда башка гражданнарга (4 пункт). Әлеге нигезләмәләр гражданнарның югарыда китерелгән һәр категориясе белән маневр фондының торак урыннарына наем шартнамәләре төзелә торган чорларны билгеләгән Торак кодексының 106 статьясы белән тыгыз элемтәдә тора.

Шулай итеп, федераль закон чыгаручы тарафыннан гражданнарның маневр фондының торак урыннарын алу хокукы барлыкка килә торган очраклар һәм нигезләр, мондый гражданнар категорияләре исемлеге, шулай ук аларның мондый торак урыннардан файдаланырга хокуклары булган чорлар билгеләнгән. Шуның белән бергә, гражданнарның аталган исемлеге тулы түгел, чөнки Торак кодексының күрсәтелгән нормалары маневр фондының торак урыннарын законнарда каралган башка очракларда да бирү мөмкинлеген калдыралар.

Торак кодексының китерелгән нигезләмәләре маневр фонды торак урыннарының социаль ярдәм чаралары буларак вакытлыча яшәү өчен гражданнарның аерым категорияләренә мондый торак урыннары бирүдән гыйбарәт булган хокукый режимы үзенчәлекләрен беркетәләр һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе торак законнары белән беркетелгән махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар, шул исәптән маневр фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен закон нигезен тәшкил итәләр, моның дәвамы буларак, дәгъва белдерелә торган Нигезләмә белән Казан шәһәре

Думасы маневр фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләгән.

Үзенең хокукый эчтәлеге буенча Нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын күздә тоткан 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацлары бланкет характерга ия, чөнки, аерым алганда, Торак кодексының югарыда аталган 106 статьясына сылтаулы нигезләмә бар. Әмма карала торган нормалар әлеге статьяның 2 өлешенең шул ук Кодексның 95 статьясы белән үзара бәйләнешендәге таләпләре белән тулысынча туры килеп бетми, чөнки алар күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану нәтиҗәсендә торак урыннары яшәү өчен яраксызга әйләнгән гражданнарга, шулай ук законнарда каралган очракларда башка гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын үз эченә алмый.

Нигезләмәдә кулланылган дәгъва белдерелә торган нормаларны бәян итүнең юридик конструкциясе вәкаләтле органга гражданнарны маневр фондының торак урыннарын бирү максатларында нормаларның бланкет характерын билгели торган таләпләрне исәпкә алмыйча теге яки бу категориягә кертү өчен, бердәнбер хокукый нигез буларак, алар тарафыннан билгеләнгән чорлар исемлеген кулланырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, китерелгән туры килмәү нәтиҗәдә гражданнарның нинди категорияләре мондый торак алуга хокуклы булуын аңлауның һәм аңлатуның чикләү характерын алдан билгели, чөнки дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрдә беркетелгән чорлар исемлеге, шулай ук маневр фондының торак урыннарын бирү очраклары зур юридик көчкә ия булган норматив хокукый актта билгеләнгән шундый ук исемлек белән чагыштырганда сизелерлек кыскартылган, бу норматив хокукый актларның иерархиясен боза һәм вәкаләтле орган тарафыннан нигезсез һәм объектив булмаган карар кабул итүгә китерергә мөмкин.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды гамәлдәге хокукый җайга салу системасында шикаять белдерелә торган нормалар,

фактта маневр фондының торак урынын алу хокукына ия гражданнар категорияләренең тулы исемлеген билгеләп, аны бирү мәсьәләсен хәл итүгә төрлечә якын килергә, шулай ук аларны ирекле кулланырга мөмкинлек бирә, бу хокукый норманың ачыклыгы һәм бер мәгънәдә булуы гомумхокукый критерийларына туры килми һәм, димәк, тигезлек һәм гаделлек конституциячел принцибын боза, дигән нәтиҗәгә килә.

Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең карарларында хокукый норманың билгелелеге таләбен бозу үзеннән-үзе мондый норманы Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килә дип тану өчен тулысынча җитәрлек булырга мөмкин дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2011 елның 20 декабрендәге 29-П номерлы, 2015 елның 2 июнендәге 12-П номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 22-П номерлы, 2018 елның 16 мартындагы 11-П номерлы һ.б. карарлар).

Шуның белән бергә дәгъва белдерелә торган Нигезләмәнең 4.1 пунктының Торак кодексының югарыда китерелгән нормаларына карата субсидиар характерда булуын исәпкә алмыйча ярамый, бу гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү очракларын, нигезләрен, алар әлеге торак урыннарыннан файдаланырга хокуклы булган чорларны, шулай ук ачык булган һәм законда каралган очракларда гражданнарның башка категорияләренә торак урыннары бирү мөмкинлеген күздә тоткан мондый гражданнар категорияләре исемлеген төгәл беркеткән әлеге Кодексның 95 һәм 106 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренең турыдан-туры гамәлдә булуын күздә тота. Моннан чыгып, Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы шикаять белдерелә торган икенче — бишенче абзацларында эчтәлеге буенча Торак кодексы нигезләмәләренә охшаш хокукый нормаларның булмавы үзеннән-үзе соңгылары Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һичшиксез кулланылырга тиеш түгел дигәнне аңлатмый.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды, акыллы тотнаклылык принцибына таянып һәм объектив килеп туган чынбарлыкны исәпкә алып, конституциячел яклана торган

кыйммәтләр балансын саклау максатларында әлеге эштә Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацының аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып калырга мөмкин дип саный, чөнки дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрне хокук өлкәсеннән төшереп калдыру гражданнарның Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә аларның маневр фондының торак урыннарын алу хокукларын нигезсез рәвештә чикләүгә китерергә мөмкин.

Моның белән Казан шәһәре җирле үзидарә вәкиллекле органыннан, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып, гражданнарның аерым категорияләренә беркетелгән маневр фондының торак урыннарын алу хокукы шик астына куелмасын өчен, ә хокук куллану практикасында дәгъва белдерелә торган хокукый нормаларны каршылыклы аңлату булмасын өчен шикаять белдерелә торган актка үз вакытында Торак кодексы нигезләмәләреннән һәм әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертү бурычы алынмый.

3.2. Нигезләмәнең 4.2 һәм 4.4 пунктларының үзара бәйле нормалары, үзләренең асылы буенча, гражданнарның Казан шәһәре маневр фондының торак урынын алуга хокукын гамәлгә ашыруның оештыру-процедура механизмы элементлары буларак, гражданнар яисә оешмаларның мөрәҗәгать итүе гариза тәртибендә булуын (4.2 пункт), мондый мөрәҗәгатьләрне карау срокларын, шулай ук кабул ителгән карарлар турында гражданнарга һәм оешмаларга хәбәр итү срокларын һәм ысулын күздә тота (4.4 пункт).

Күрсәтелгән нигезләмәләрнең конституциячеллегенә дәгъва белдереп, гражданин Т.Ә. Вәлиев аларда закон белән билгеләнгән хокукны гамәлгә ашыру максатларында мөрәҗәгать иткән гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау процедурасы кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан үтәлергә тиешле тулы бер эзлекле гамәлләрнең булмавын күрә. Аның фикеренчә, Нигезләмәдә гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди нигезләрдә

һәм нинди карарлар кабул ителергә мөмкин булуы турында сорауларга җавап бирә торган нормалар чагылыш тапмаган.

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүченең дәлилләре белән килешә алмый, чөнки шикаять белдерелә торган нормаларны маневр фондының торак урыннары гражданнарга Казан шәһәре Башкарма комитеты карары буенча бирелүен күздә тоткан Нигезләмәнең 1.4 пункты белән, граждан тарафыннан вәкаләтле органга тапшырылырга тиешле документлар исемлеген билгеләүче Нигезләмәнең 4.3 пункты белән, шулай ук гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү очракларын һәм нигезләрен ачыклаучы Торак кодексының 95 статьясы белән үзара бәйләнештә Нигезләмәнең 4.1 пункты белән аерылгысыз бердәмлектә карарга кирәк. Китерелгән җайга салу белән гамәлләр алгоритмын үтәү зарурлыгы таләп ителә, аның буенча вәкаләтле орган, граждан гаризасын яисә оешма мөрәҗәгатен кабул итеп, вакытлыча яшәү өчен маневр фондының торак урыннарын алуга нигез булган хәлләрне, шулай ук Казан шәһәрендә гражданның торак урыннар белән тәэмин ителешенә карата гаризага кушып бирелгән документларны бәяли һәм билгеләнгән срокта тиешле карар кабул итә. Шул ук вакытта Торак кодексы һәм Нигезләмә нормаларыннан килеп чыга торган хәлләрнең норматив-хокукый характеристикасы вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә торган гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен канәгатьләндерү турында да, канәгатьләндерүдән баш тарту турында да карарларның дәлилләнгән булуын алдан билгели.

Димәк, гражданин Т.Ә. Вәлиев тарафыннан дәгъва белдерелә торган нормалар үзеннән-үзе гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди карарлар кабул ителергә мөмкин булуы турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк һәм хокук куллану практикасында әлеге хокукый җайга салу белән ярашмый торган башкача аңлатуга юл куймыйлар

һәм вәкаләтле орган тарафыннан дәлилләнмәгән уңай карарны да, тискәре карарны да кабул итү мөмкин булган аларның мондый кулланылышын кире кагалар. Гавами хакимиятнең тиешле органы торакларын югалтуга китергән тормыш хәлендә калган яки капиталь ремонт яисә реконструкцияләүгә бәйле рәвештә торак урынында яшәү мөмкин булмаган гражданнар вакытлыча файдалануга маневр фондының торак урынын алуның реаль мөмкинлегенә ия булсын өчен, шулай ук әлеге социаль ярдәм чарасын иллюзор характерда булмаслык итеп тормышка ашыруны тәэмин итәр өчен барлык тиешле чараларны күрергә тиеш.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге нәтиҗәгә килә: гамәлдәге хокукый җайга салу системасында гражданнарның Казан шәһәре маневр фондының торак урынын алуга хокукын гамәлгә ашыруның оештыру-процедура механизмы элементлары булган Нигезләмәнең 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы үзара бәйле нормалар, үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча вәкаләтле органның шикаять белдерелә торган норматив хокукый акт белән билгеләнгән срокларда маневр фондының торак урынын бирү яки аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар кабул итәргә тиеш булуын күздә тота һәм шуның белән карала торган аспектта билгесезлек юк, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Шуның белән бергә, гражданнарга Казан шәһәре маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен билгели торган нигезләмәләрне бертөрле куллану максатларында Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге хокукый җайга салуны камилләштерү мәсьәләсен тиешле карар кабул итү процедурасын тагын да тулырак регламентлаштыруга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү юлы белән анда кабул ителгән карарны дәлилле нигезләүнең мәҗбүрилегенә турыдан-туры күрсәтмәсен чагылдырып карау максатка ярашлы дип саный. Мондый үзгәрешләр дәгъва белдерелә торган нормаларның ирекле кулланылышын кире кагарлар иде һәм бу

мәсьәләдә мөнәсәбәтләрне җайга салуда ачыклык, төгәллек булуга һәм бер мәгънәдә аңлауга ярдәм итәр иде. Хәзерге вакытта гамәлдә булган маневр фондының торак урынын наемга алу шартнамәсе буенча торак урыннар бирү тәртибен, маневр фондының торак урынын алуга гариза формасын да кертеп (1 номерлы кушымта), гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның төрләрен, шулай ук маневр фондының торак урынын бирүдән баш тарту өчен нигезләрне билгеләүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1314 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең маневрлы муниципаль торак фондын төзү турында нигезләмә белән күрсәтелгән үзгәрешләр кертү зарурлыгы юкка чыгарылмый. Мондый алым Уставның 40 статьясындагы 3.8 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә мондый торак урыннарны бирү генә кертелгән булуы, ә махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибен һәм маневр фондының торак урыннарын бирү процедурасының үзен билгеләү Уставның 28 статьясы нигезендә Казан шәһәре Думасының аерым компетенциясе булып торуы белән бәйле. Шуның белән бергә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1314 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең маневрлы муниципаль торак фондын төзү турында нигезләмәнең, шул исәптән гамәлдәге хокукый җайга салу системасында аның урыны һәм аны кабул итү тәртибе күзлегеннән, конституциячеллегенә алга таба бәя бирү мөмкин түгел, чөнки бу норматив хокукый акт әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тормый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция суды Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацының аерым нигезләмәләрен, гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын билгеләп, алар гражданны шушы чорлар кысаларында мондый торак урыннарын алу хокукына ия булган теге яки бу категориягә кертү өчен норматив нигез булып торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Моның белән Казан шәһәре җирле үзидарә вәкиллекле органыннан, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып, гражданнарның аерым категорияләренә беркетелгән маневр фондының торак урыннарын алу хокукы шик астына куелмасын өчен, ә хокук куллану практикасында дәгъва белдерелә торган хокукый нормаларны каршылыклы аңлату булмасын өчен шикаять белдерелә торган актка үз вакытында Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләреннән һәм әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертү бурычы алынмый.

2. Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларын, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның

рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 103-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**